

Мордовия кырларында уныш жыю дəвам итə. Шул эшнен остасы турында свзебез.
Мордовия Республикасынын Лəмберə районы механизаторы Сергей Митрофанов жир сорv буенча Россиянен 13 нче ачык чемпионаты жинvчесе.
Лəмберə механизаторы Сергей Митрофанов «Россиянен ин яхшы сабанчысы» титулын яулады. Сергей очен бу жинv кvпьеллык тырыш хезмəт һəм кvнекмəлəрен даими камиллəштерv нəтижəсе булды.       Минерал Водыдагы Чемпионат игенчелекнен элитасын жыйды: беренче дип аталу хокукы очен илнен егерме сигез тобəгеннəн - Приморьедан алып Пермь краена кадəр 46 ин кочле механизаторны очраштырды. Сергей Митрофанов ярышларда 2017 елдан бирле катнаша. Анын жилкəсендə – Уфа, Суздаль, Казан, Мордовия турнирлары. Сонгы елларда ул тотрыклы рəвештə лидерлар рəтендə урын алып килде. Ул бу пьедесталга əкренлəп менде: 2023 елда - бронза, 2024 елда - комеш медаль яулый һəм хаталар остендə эшли. Нəтижəдə жинvле 2026 ел - кvптəн котелгəн алтын һəм абсолют чемпион исеме. Бу уныш очраклы тvгел, ə еллар буе туган кырларынын кызу кояшы астында, жилдə камиллəшə торган осталык. Илнен беренче сабанчысы əйтvенчə, əлеге жинv анын очен икелəтə бəйрəм: Сергей Митрофанов кvптəн тvгел комбайн руле артына беренче тапкыр утыруына 30 ел тулган. Жинv жинел бирелмəгəн. Катнашучылар очен шартлар кырыс булган һəм ювелир тогəллек талəп иткəн. Чиклəнгəн вакыт эчендə (нибары оч сəгать эчендə) механизаторларга 1500 квадрат метр чамасы мəйданда жир сорергə туры килгəн. Хəзерге авыл хужалыгында сорvлек кvптəн инде жир катламын əйлəндерv генə булудан туктады. Бу югары технологияле процесс. Чемпионат жюрисы финалистларнын эшен 14 катгый критерий буенча бəялəгəн. Жир белəн виртуоз эшлəгəне очен Россия игенчесе хыялланган бvлəккə лаек була. Сергей Митрофановнын жинve - республиканын горурлыгы. Ул Мордовия игенчелек мəктəбенен илдə ин кочлелəрнен берсе булып калуын ачык кvрсəтə. Чемпионатнын приз фонды жинvчегə заманча Belarus 82.3 тəгəрмəчле тракторы белəн бvлəкли. Чемпион очен мондый бvлəк - хужалыкта житди ярдəм. Яна техника туфракны əзерлəvдəн һəм йок ташудан алып коммуналь эшлəргə кадəр булган бурычларнын кин спектрында кулланырга момкинлек бирəчəк. Хəзер алдынгы механизатор-нын шəхси, ор-яна «тимер аты» бар, ул уныш очен корəштə ышанычлы ярдəмче булачак.
- Мине шатлык билəп алды, мин бу жинvгə 2016 елдан бирле максатчан килдем. Илнен ин яхшы сабанчысы исеме – кубок кына тvгел, бу кvпьеллык хезмəт, тvземлек һəм һонəргə тугрылык дəлиле. Тренировкалар һəм эшнен озын юлы ботен Россиядəн ин кочле катнашучылар компаниясендə югары нəти-жəгə китергəн дигəн хис бу моментны тагын да кыйммəтлерəк итə, - ди  ул жинvдəн алган хислəре турында.
Шундый оста игенчелəребез булганда остəлдə икмəк тə, дəvлəтнен килəчəге дə бар.

**Наилə НАСЫРОВА,**

**фото - АО «Росагролизинг» сайтыннан**